**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора,
Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЕ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы,
Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**22.10.2018** **№ 2272**

**Биектау муниципаль районы бюджетыннан юридик затларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләргә субсидияләрдән тыш), индивидуаль эшкуарларга, физик затларга - товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүчеләргә субсидияләр бирү тәртибен раслау турында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Юридик затларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләргә субсидияләрдән тыш), индивидуаль эшкуарларга, шулай ук физик затларга - товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүчеләргә субсидияләр бирүне җайга сала торган норматив хокукый актларга, муниципальхокукый актларга гомуми таләпләр турында» 2016 елның 6 сентябрендәге 887 номерлы карары нигезендә, Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Кушымтада бирелгән Биектау муниципаль районы бюджетыннан юридик затларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләргә субсидияләрдән тыш), индивидуаль эшкуарларга, физик затларга - товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүчеләргә субсидияләр бирү тәртибен расларга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы порталының рәсми сайтында: http://pravo.tatarstan.ru һәм Интернет челтәрендә Биектау муниципаль районы рәсми сайтында: http//vysokaya-gora/tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары А.П. Афанасьевка йөкләргә.

Биектау муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Д.Ф.Шәйдуллин

Кушымта
Татарстан Республикасы Биектау
муниципаль районы Башкарма
комитетының 2018 елның 22
октябрендәге 2272 номерлы карары
белән расланды

**Биектау муниципаль районы бюджетыннан юридик затларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләргә субсидияләрдән тыш), индивидуаль эшкуарларга, физик затларга - товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүчеләргә субсидияләр бирү тәртибе**

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Биектау муниципаль районы бюджетыннан юридик затларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләргә субсидияләрдән тыш), индивидуаль эшкуарларга, физик затларга - товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүчеләргә субсидияләр бирүнең әлеге Тәртибе (алга таба - Тәртип) Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78 статьясы нигезендә эшләнгән һәм җирле бюджет акчалары исәбеннән юридик затларга (муниципаль учреждениеләргә субсидияләрдән тыш), индивидуаль эшкуарларга, физик затларга - товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүчеләргә (алга таба - субсидияләр алучыларга) субсидияләр бирү тәртибен билгели.

1.2. Тәртип шул исәптән билгели:

- субсидия алу хокукына ия субсидияләр алучыларны сайлап алу критерийларын;
- субсидияләр бирүнең максатлары, шартлары һәм тәртибе;
- субсидияләрне, аларны биргәндә билгеләнгән шартлар бозылган очракта, кире кайтару тәртибе.

1.3. Субсидияләр бирү товарлар җитештерүгә (реализацияләүгә), эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә бәйле рәвештә чыгымнарны яисә алынмаган керемнәрне каплау максатларында түләүсез һәм кире кайтарылмый торган нигездә гамәлгә ашырыла.

1.4. Җирле бюджеттан субсидияләр тиешле чорга Биектау муниципаль районы бюджеты (алга таба - Биектау муниципаль районы бюджеты) турындагы карар нигезендә бирелә, ул эшчәнлекнең өстенлекле юнәлешләре буенча субсидия алучыларны билгели, аларны финанс белән тәэмин итү чыганагы - Биектау муниципаль районы башкарма комитеты белән килешү нигезендә түзелә торган Биектау муниципаль районы халыкка социаль (мунча) хезмәт күрсәтүгә бәйле алып бетерелмәгән керемнәрне каплау субсидиясе.

2. Субсидияләр алу хокукына ия субсидияләр алучыларны сайлап алу критерийлары

2.1. Биектау муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр алу хокукына ия субсидияләр алучыларны сайлап алу критерийлары түбәндәгеләр:

1) Биектау муниципаль районы территориясендә эшчәнлек башкару;

2) чираттагы финанс елына Биектау муниципаль районы бюджеты турындагы карар белән билгеләнгән эшчәнлек төрләренә субсидияләр алучыларның эшчәнлек өлкәсе туры килүе;

3) салымнар һәм җыемнар турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән бурыч булмау (мондый таләп хокукый акт белән каралган очракта);

4) субсидияләр алучылар - юридик затлар үзгәртеп кору, бетерү, банкротлык процессында булырга тиеш түгел, ә субсидияләр алучылар - индивидуаль эшкуарлар индивидуаль эшкуар сыйфатында эшчәнлеген туктатырга тиеш түгел (әгәр мондый таләп хокукый акт белән каралган булса);

5) товарлар җитештерүнең, эшләр башкаруның, хезмәтләр күрсәтүнең актуальлеге һәм социаль әһәмияте булу;

6) субсидия алучыларның хокукый акт нигезендә Биектау муниципаль районы бюджетына кире кайтару буенча срогы чыккан бурычы, субсидияләре, шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгән бюджет инвестицияләре, һәм Биектау муниципаль районы бюджеты алдындагы башка срогы чыккан бурычы булмаска тиеш (андый таләпләр хокукый акт нигезендә каралган очракта);

7) субсидия алучылар чит ил юридик затлары, шулай ук аларның устав (җыелма) капиталында теркәлү урыны булып Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан раслана торган, мондый юридик затларга карата салым салуның ташламалы салым режимы һәм (яисә) финанс операцияләре уздырганда мәгълүмат ачуны һәм бирүне күздә тотмаган (офшор зоналары) дәүләтләр яисә территорияләр исемлегенә кертелгән дәүләтләр һәм территорияләр булган чит ил юридик затларының катнашу өлеше җыелмасы 50 проценттан арткан Россия юридик затлары булырга тиеш түгел;

8) субсидияләр алучылар әлеге документның 3 пунктының 3,1 пунктчасында _ күрсәтелгән максатларга башка муниципаль хокукый актлар нигезендә Биектау муниципаль районы бюджетыннан хокукый акт нигезендә акчалар алырга тиеш түгел;

### 3. Субсидияләр бирүнең максатлары, шартлары һәм тәртибе

3.1. Әлеге Тәртип нигезендә, субсидияләр бирү максаты булып, чираттагы финанс елына һәм план чорына Биектау муниципаль районы бюджеты турындагы карар белән билгеләнгән эшчәнлекнең өстенлекле юнәлешләре буенча субсидия алучыларның категорияләренә товарлар җитештерүгә (реализацияләүгә), эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә бәйле рәвештә чыгымнарны яисә алынмаган керемнәрне финанс белән тәэмин итү (каплау) тора.

3.2. Субсидияләр бирү әлеге максатларга Биектау муниципаль районы бюджетында каралган акчалар исәбеннән гамәлгә ашырыла.

3.3. Юридик затларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләргә субсидияләрдән тыш), индивидуаль эшкуарларга, шулай ук физик затларга - товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүчеләргә субсидияләр бирүгә каралган бюджет ассигнованиеләре күләме Биектау муниципаль районы Советының чираттагы финанс елына һәм план чорына бюджет турындагы карары белән раслана.

3.4. Биектау муниципаль районының юридик затларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләргә субсидияләр бирүдән тыш), индивидуаль эшкуарларга, физик затларга - товар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүчеләргә субсидияләр бирү буенча бюджет акчаларын баш бүлүчесе булып Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты (алга таба - Башкарма комитет) тора.

3.5. Субсидияләр җыелма бюджет язмасы нигезендә бюджет ассигнованиеләре чикләрендә һәм чираттагы финанс елына бюджет йөкләмәләренең билгеләнгән лимитлары чикләрендә сайлап алу нәтиҗәләре нигезендә бирелә.

3.6. Субсидия алучыларны сайлау әлеге Тәртиптә билгеләнгән сайлап алу критерийлары нигезендә башкарма комитет тарафыннан гамәлгә ашырыла. Субсидия алучыларны сайлап алуны үткәрү өчен Башкарма комитет карары нигезендә компетентлы белгечләр арасыннан комиссия төзелә.

3.7. Субсидия алучыларны сайлап алуны үткәрү өчен Башкарма комитет карары белән документларны сайлап алуда катнашу өчен документларны кабул итү срокларын һәм адресын күрсәтеп, гаризалар кабул итү игълан ителә.

3.8. Сайлап алуда катнашу өчен, субсидияләр алучылар Башкарма комитетка түбәндәге документларны тапшыралар:

1) әлеге Тәртипкә 1 нче кушымта нигезендә сайлап алуда катнашу өчен гариза;

2) әлеге Тәртипкә 2 нче кушымта нигезендә субъект турында белешмәләр;

3) эшкуарлык субъекты тарафыннан таныкланган устав күчермәсен (юридик затлар өчен);

4) эшчәнлек юнәлешләре буенча керемнәрне һәм чыгымнарны исәпләү;

5) әлеге тәртипкә 3 нче кушымта нигезендә форма буенча субъект җитәкчесе имзасын алу белешмәсен;

6) субсидия бирүгә белешмә-исәп;

7) шәхси мәгълүматларны (физик затлар өчен) эшкәртүгә ризалык, шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык «Шәхси мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән очракларда һәм формада бирелә.

3.8.1 Башкарма комитет ведомствоара хезмәттәшлек тәртибендә заявканы теркәгән көннән алып биш эш көненнән артмаган срокта түбәндәгеләрне соратып ала:

1) Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә - юридик затлар яисә индивидуаль эшкуарларның бердәм дәүләт реестрыннан - индивидуаль эшкуарлар өчен;

2) салымнар һәм җыемнар буенча бурыч булмавын раслый торган исәпкә кую урыны буенча салым органыннан белешмәләр;

3) Россия Федерациясе Пенсия фонды алдында иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар буенча бурычы барлыгы (булмау) турында белешмәләр;

4) эшчәнлекне лицензияләү турында белешмәләр (әгәр эшкуарлык субъекты тарафыннан гамәлгә ашырыла торган эшчәнлек төре лицензияләнергә тиеш булса);

5) кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү өлкәсендә федераль программаны, Татарстан Республикасы дәүләт программаларын, Биектау муниципаль районы программаларын гамәлгә ашыру кысаларында барлык дәрәҗәдәге бюджет акчаларыннан эшкуарлык субъектларына шундый ук ярдәм турында белешмәләр.

3.8.2. Әлеге Тәртипнең 3.8.1 пунктында күрсәтелгән документларны эшкуарлык субъекты үз инициативасы белән башкарма комитетка тапшырырга хокуклы.

Документларның тәкъдим ителгән барлык күчермәләре җитәкче тарафыннан таныклана һәм субъектның мөһере (ул булса) белән беркетелә һәм бер үк вакытта оригиналлар белән бирелә.

Комиссия субсидия алучыларны әлеге Тәртиптә билгеләнгән сайлап алу критерийлары нигезендә сайлап ала.

Субсидияләр бирүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез була:

- субсидия алучы тарафыннан тапшырылган документларның 3.8 пунктының 1-7 пунктчаларында билгеләнгән таләпләргә туры килмәве яисә күрсәтелгән документларны тапшырмау (тулы күләмдә тапшырмау);

- субсидия алучы тарафыннан бирелгән мәгълүматның дөрес булмавы;

- кече һәм урта эшкуарлык субъекты ярдәм күрсәтү тәртибен һәм шартларын бозуга юл куйган, шул исәптән ярдәм чараларын максатчан файдалануны тәэмин итмәгән (хокук бозу фактын тану вакытыннан алып өч елдан да азрак вакыт узган).

Субсидия алуга заявкалар һәм аңа кушып бирелгән документлар тулы күләмдә генә кабул ителә, һәм кире кайтарылмый.

3.9. Субъект гаризаны һәм аңа кушып бирелгән документларны әзерләүгә һәм бирүгә бәйле барлык чыгымнарны мөстәкыйль рәвештә күтәрә.

3.10. Субсидияләр бирү турында гаризаларны карау һәм карар кабул итү срогы заявкалар кабул итү тәмамланган көннән алып 30 эш көненнән арта алмый.

3.11 Комиссия утырышы, әгәр анда составның яртысыннан да ким булмаган өлеше катнашса, тулы хокуклы булып тора. Комиссия әгъзалары вазыйфаи затларга, алар булмаган очракта (отпуск, командировка һ.б.) үз вәкаләтләрен тапшыра алалар

3.12. Карарны комиссия ачык тавыш бирү нәтиҗәләре буенча кабул итә.

Әгәр дә комиссия утырышында катнашучыларның күпчелеге аның өчен тавыш бирсә, карар кабул ителгән дип санала. Тавышлар тигез булган очракта, комиссия рәисенең тавышы хәлиткеч булып тора.

3.13. Субсидия бирү яисә бирүдән баш тарту турындагы карар комиссия утырышы беркетмәсе белән рәсмиләштерелә һәм комиссия рәисе тарафыннан имзалана. сайлап алу нәтиҗәсендә билгеләнгән конкрет субсидич алучы комиссия тарафыннан Башкарма комитет карарында күрсәтелә.

3.14. Агымдагы елда субсидия бирү өчен бюджет ассигнованиеләре акчалары җитмәгән очракта, субсидия заявкасы беренче булып кергән субъектка бирелә.

Беркетмәгә имза салынган вакыттан алып 5 көн эчендә заявкаларны сайлап алуны оештыручы заявкаларны алу нәтиҗәләре турында субсидияләр алучыларга хәбәр итә.

3.15. Субсидия бирү Биектау муниципаль районының бюджет акчаларын баш бүлүчесе һәм әлеге Тәртип нигезендә субсидияләр алучы арасында төзелгән килешүләр (килешүләр) нигезендә гамәлгә ашырыла.

Субсидия бирүгә килешү (шартнамә) төзегәндә, килешү төзү планлаштырыла торган айга кадәрге айның беренче числосына туры килергә тиешле әлеге Тәртипнең 2 пунктының 2.1 пунктчасында каралган таләпләр үтәлергә тиеш (яисә субсидияләр бирү турында карар кабул итү, әгәр товарларны җитештерүгә (реализацияләүгә), эшләрне башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә бәйле чыгымнарны (алынмаган керемнәрне) каплау тәртибендә субсидияләр бирүне җайга сала торган хокукый акт тарафыннан килешү төзү каралмаган булса).

Күрсәтелгән килешүләрдә (шартнамәләрдә) түбәндәгеләр каралырга тиеш:

- субсидияләр бирүнең максатлары һәм шартлары, сроклары;

- аның күләмен нигезли торган мәгълүматны күрсәтеп, субсидия күләмен исәпләү күләме һәм тәртибе (исәпләү формулалары һәм аларны куллану тәртибе, чыгымнар нормалары һәм субсидия бирү максатларыннан чыгып башка мәгълүмат);

- максатчан чыгымнарны өлешле финанслау буенча субсидия алучыларның йөкләмәләре;

- субсидияне максатчан файдалану буенча субсидия алучыларның йөкләмәләре;

- субсидия алучы билгеләнгән шартларны үтәү нәтиҗәләре турында хисап бирү рәвеше һәм тәртибе;

- субсидияләрне аларны биргәндә билгеләнгән шартлар бозылган очракта кире кайтару тәртибе;

- субсидияләр бирү шартлары яклар тарафыннан үтәлмәгән өчен җаваплылык;

- субсидия алучылар һәм устав (җыелма) капиталларында гавами-хокукый берәмлекләр, шулай ук устав (җыелма) капиталларында мондый ширкәтләр һәм җәмгыятьләр катнашында аларның устав (тупланма) капиталларында, шулай ук коммерция оешмалары катнашында, субсидияләрне (муниципаль) унитар предприятиеләре, хуҗалык ширкәтләре һәм җәмгыятьләре дәүләт (муниципаль) финанс контроле органнары тарафыннан үтәү турында шартнамәләр (килешүләр) буенча йөкләмәләрне үтәү максатларында төзелгән шартнамәләр (килешүләр) буенча товар куючылар (подрядчылар, башкаручылар) булып торучы затларның һәм коммерциячел оешмалар катнашында субсидияләр алучыларга, субсидияләрне бирү шартларын, максатларын үтәүне дәүләт (муниципаль) финанс контроле органнары тарафыннан гамәлгә ашыруга ризалыгы;

- алынган акчалар исәбеннән чит ил валютасы сатып алуны тыю, югары технологияле импорт җиһазларын, чималны һәм комплектлау әйберләрен сатып алганда (китергәндә) Россия Федерациясе валютасы законнары нигезендә гамәлгә ашырыла торган операцияләрдән, шулай ук әлеге акчаларны максатларына ирешүгә бәйле рәвештә күрсәтелгән юридик затларга субсидияләр бирүне җайга сала торган норматив хокукый актларда, муниципаль хокукый актларда билгеләнгән башка операцияләр тыш.

3.16. Субсидияләр алу турында операцияләрне кире алу Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

3.17. Субсидияләр алучылар бюджет акчаларын төп бүлүчегә субсидияләр куллану турында килешү (шартнамә) белән билгеләнгән тәртиптә финанс хисабы тапшыралар.

3.18. Баш бүлүче килешүләр (шартнамәләр) шартларының үтәлешен, шулай ук килешүләр (шартнамәләр) шартлары бозылган очракта, субсидияләрне җирле бюджетка кире кайтаруны контрольдә тотуны гамәлгә ашыра.

3.19 Субсидия күчерү срогы субсидия бирү турында килешү (шартнамә) төзегән көннән исәпләнә һәм 10 эш көненнән дә артык түгел.

Субсидияләр Россия Федерациясе Үзәк банкы учреждениеләрендә яисә кредит оешмаларында индивидуаль эшкуарлар, шулай ук физик затлар - товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүчеләр өчен ачылган акчаларны алучының исәп-хисап счетына күчерелә.

## 4. Субсидияләрдән файдалануны контрольдә тоту

4.1. Бюджет акчаларының баш бүлүчесе аларны алучылар тарафыннан субсидияләр бирү шартларының, максатларының һәм тәртибенең үтәлешен мәҗбүри тикшерүне гамәлгә ашыра.

4.2. Субсидияләр алучылар тикшерүләр үткәрү өчен Биектау муниципаль районы бюджетыннан субсидия бирүгә бәйле барлык беренчел документларны тикшерүчеләргә тапшырырга тиеш.

4.3. Субсидияләрдән файдалану нәтиҗәләре буенча бюджет акчаларын алучы, хисап елыннан соң килүче елның 20 гыйнварына кадәр, бирелгән субсидияләрне максатчан куллануны раслаучы документлар белән, Биектау муниципаль районы бюджеты акчаларыннан файдалану турында хисап тапшыра.

4.4. Бюджет акчаларыннан максатчан файдалануга финанс контроле Биектау муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

4.5. Биектау муниципаль районы бюджетыннан субсидия алучыларга бүлеп бирелгән субсидияләр максатчан характерга ия һәм башка максатларда файдаланыла алмый.

## 5. Субсидияләрне кире кайтару тәртибе

5.1. Субсидияләр алучыларга күчерелгән субсидияләр финанс елы дәвамында субсидия тулы күләмдә файдаланылмаган (субсидияне алучының финанс белән тәэмин итү чыганагы күрсәтелгән субсидияләрне алучыларның акчалата йөкләмәләрен түләү өчен кирәкле суммадан тыш), аларны биргәндә билгеләнгән шартлар бозылган очракта, Биектау муниципаль районы бюджетына кайтарылырга тиеш.

5.2. Субсидияләр бирү шартлары бозылган очракта яисә аларны максатчан файдаланмаган очракларда бюджет акчаларын баш бүлүче әлеге факт билгеләнгән көннән алып ун көннән дә соңга калмыйча субсидия алучыга Биектау муниципаль районы бюджетына субсидия кайтару таләбен җибәрә.

5.3. Субсидия алучы, субсидияне кире кайтару турында таләп алынган көннән алып ун эш көне эчендә, таләп ителгән субсидия суммасын кире кайтарырга тиеш. Максатчан билгеләнеше буенча файдаланылмаган субсидиянең бөтен суммасы,

хәбәрнамә һәм тикшерү акты алган вакыттан алып 10 көн эчендә керемнәр коды буенча Биектау муниципаль районы бюджетына кайтарылырга тиеш.

5.4. Бюджет чараларын алучы инициативасы буенча килешүне (шартнамәне) өзгәндә, субсидия бирү йөкләмәләренең башка ягы һәм шартларының бозылуына бәйле рәвештә, юридик затлар, индивидуаль эшкуарлар һәм физик затлар файдаланылмаган субсидия акчаларын Биектау муниципаль районы бюджетына бюджет акчаларын алучыга хәбәр алынган вакыттан алып 10 көн эчендә кире кайтарырга тиеш.

5.5. Субсидияләр тулы күләмдә файдаланмаган очракта, финанс ел дәвамында субсидия алучылар файдаланылмаган акчаларны, түләү билгеләнүне күрсәтеп, бу елның 25 декабреннән дә соңга калмыйча, Биектау муниципаль районы бюджетына кайтаралар (финанс белән тәэмин итү чыганагы күрсәтелгән субсидияләр булган субсидия алучының акчалата йөкләмәләрен түләү өчен кирәкле сумма чикләрендә бирелгән субсидияләрдән тыш).

5.6. Субсидия алучы ирекле тәртиптә акча түләүдән баш тартканда, түләтү Россия Федерациясе законнары нигезендә суд тәртибендә гамәлгә ашырыла.

Биектау муниципаль районы бюджетыннан юридик затларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләргә субсидияләрдән тыш), индивидуаль эшкуарларга, физик затларга - товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүчеләргә субсидияләр бирү тәртибенә 1 нче кушымта

Форма

Биектау муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесенә
кемнән ______________________________
_____________________________________
(җитәкченең Ф.И.А., оешманың исеме)

Өстенлекле эшчәнлек төрләре белән шөгыльләнүче юридик затлар (дәүләт (муниципаль) учреждениеләргә субсидияләрдән тыш), индивидуаль эшкуарлар, физик затлар - товарлар, эшләр, хезмәтләр җитештерүчеләр тарафыннан Биектау муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр алуга

ГАРИЗА

Түбәндәге заттан____________________________
_______________________________________________________________________________
(оешманың тулы һәм кыскартылган исеме, шәхси эшкуарның фамилиясе, исеме, атасының исеме)

_________________________________________________________________ өстенлекле эшчәнлек төрләре белән шөгыльләнүче юридик затларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләргә субсидияләрдән тыш), индивидуаль эшкуарларга, физик затларга - товарлар, эшләр, хезмәтләр җитештерүчеләргә Биектау муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү өчен документларны карауга кабул итүегезне сорыйм.
Соратыла торган субсидия күләме ______________________________________ мең сум.
Субсидия алу максаты______________________________________________________
Сайлап алу шартлары белән таныштырылдым һәм өстенлекле эшчәнлек төрләре белән шөгыльләнүче юридик затларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләргә субсидияләрдән тыш), индивидуаль эшкуарларга, физик затларга - товарлар, эшләр, хезмәтләр җитештерүчеләргә чыгымнарның бер өлешен каплауга Биектау муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибе нигезендә түбәндә китерелгән исемлек нигезендә кирәкле документлар тапшырам.

Тапшырылган документлар исемлеге

| № т/б | Документ исеме | Битләр саны |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |

| | | |
|---|---|---|
| | | |

Гариза бирү датасы: «____» __________________20___ ел

Җитәкче
(индивидуаль
эшкуар)__________________________ ____________________
(дата) (имза) (Ф.И.А.)

Биектау муниципаль районы бюджетыннан юридик затларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләргә субсидияләрдән тыш), индивидуаль эшкуарларга, физик затларга - товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүчеләргә субсидияләр бирү тәртибенә 2 нче кушымта

Форма

Субсидияләр алучы турында мәгълүмат

| | | |
|---|---|---|
| 1. | Субсидия алучының тулы исеме | |
| 2. | Индивидуаль эшкуарның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы булганда), юридик зат җитәкчесенең вазыйфасы һәм фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы булганда) | |
| 3. | Юридик затны гамәлгә куючы (һәм) (аларның һәркайсының устав капиталында катнашу өлеше - юридик затлар өчен) | |
| 4. | Эшчәнлекнең төп төре (ОКВЭД) | |
| 5. | Теркәү мәгълүматлары: | |
| 5.1. | Юридик затны (ОГРН) яисә индивидуаль эшкуарны (ОГРНИП) дәүләт теркәве турында язманың төп дәүләт теркәве номеры | |
| 5.2. | Юридик затны теркәү датасы, урыны, индивидуаль эшкуар буларак физик затны теркәү | |
| 6 | Юридик адрес | |
| 7. | Факттагы адресы | |
| 8. | Банк реквизитлары | |
| 9. | Салым салу системасы | |
| 10. | Патентлар, лицензияләр, сертификатлар булуы | |
| 11. | Муниципаль ярдәм алынган очракта булдырылган (саклананган) эш урыннары саны | |
| 12. | Сез хәбәр итәргә теләгән өстәмә мәгълүмат | |
| 13. | Контактлы затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы булганда) | |
| 14. | Контакт телефоннары, факс, адрес электрон почта | |

Мин үзем тәкъдим иткән белешмәләрнең дөрес булуын раслыйм, муниципаль ярдәм алуга гаризаны карау максатларында белешмәләрне сайлап алу тикшерүенә каршы тормыйм.

Җитәкче
(индивидуаль
эшкуар) ____________ ______________________________
(имза) (Ф.И.А.)

«____»_____________20____ ел
МУ

Биектау муниципаль районы бюджетыннан юридик затларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләргә субсидияләрдән тыш), индивидуаль эшкуарларга, физик затларга - товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүчеләргә субсидияләр бирү тәртибенә 3 нче кушымта

БЕЛЕШМӘ

_______________________________________________________

(субъект исеме)

20___ елның «____» ______________на торышы буенча

| | |
|---|---|
| Алдагы календарь ел (башка хисап чоры) өчен өстәлгән бәягә салымны исәпкә алмыйча, товарларны (эшләрне, хезмәт күрсәтүләрне) реализацияләүдән керем (мең сумнарда) | |
| Хезмәткәрләрнең алдагы календарь ел өчен (башка хисап чорына) уртача исемлек саны (кеше) | |
| Алдагы календарь ел өчен бер хезмәткәргә уртача айлык хезмәт хакы күләме (мең сум) | |
| Гамәлгә куючыларның составы һәм аларның устав капиталында өлеше:<br>- _____________________________________ %<br>- _____________________________________ %<br>- _____________________________________ % | |
| Коррупциягә каршы көрәш өлкәсендә алдагы календарь ел өчен гамәлгә ашырылган профилактик чаралар чаралар саны (бер.). (Мондый чаралар документлар бирәсе елдан алдагы календарь ел дәвамында гамәлгә ашырылган очракта, субъектның үз теләге белән күрсәтелә) | |

Хезмәт хакын түләү буенча хезмәткәрләр алдында бурычлар юк.
Мин үзем тәкъдим иткән белешмәләрнең дөрес булуын раслыйм, муниципаль ярдәм алуга гаризаны карау максатларында белешмәләрне сайлап алу тикшерүенә каршы тормыйм

Җитәкче
(индивидуаль
эшкуар) ___________ _____________________________

(имза) (Ф.И.А.)

«____»___________20___ ел
МУ